БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » апрель 2018 ел № 126

Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында

"Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү эшен оештыру турында нигезләмәне раслау хакында" 2018 елның 5 февралендәге 58 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ф. Гайнетдиновка, "Балтач муниципаль районы гражданнар саклау идарәсе" МКУ һәм Балтач янгын-коткару гарнизоны белән берлектә, расланган Нигезләмә нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу очрагына эвакуация чараларын планлаштырырга.

3. "Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында" 2017 елның 5 маендагы 152 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкчесе Р. И. Шакиров